**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советының Мәгълүмати куркынычсызлык буенча ведомствоара комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында**

Аерым затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре турында» 2000 елның 6 июнендәге ПУ-394 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2000 елның 6 июлендәге ПУ-491 номерлы, 2000 елның 2 ноябрендәге ПУ-829 номерлы, 2002 елның 31 гыйнварындагы ПУ-65 номерлы, 2002 елның 15 ноябрендәге ПУ-992 номерлы, 2003 елның 1 апрелендәге ПУ-235 номерлы, 2003 елның 4 августындагы ПУ-563 номерлы, 2004 елның 10 мартындагы ПУ-163 номерлы, 2004 елның 21 июнендәге ПУ-461 номерлы, 2004 елның 14 сентябрендәге ПУ-604 номерлы, 2005 елның 28 маендагы ПУ-214 номерлы, 2005 елның 22 декабрендәге ПУ-513 номерлы, 2006 елның 18 февралендәге ПУ-64 номерлы, 2006 елның 4 апрелендәге ПУ-128 номерлы, 2006 елның 18 маендагы ПУ-179 номерлы, 2007 елның 3 декабрендәге ПУ-646 номерлы, 2007 елның 25 декабрендәге ПУ-698 номерлы, 2008 елның 17 декабрендәге ПУ-660 номерлы, 2009 елның 3 июнендәге ПУ-318 номерлы, 2010 елның 4 февралендәге ПУ-42 номерлы, 2010 елның 21 июлендәге ПУ-475 номерлы, 2010 елның 9 декабрендәге ПУ-798 номерлы, 2012 елның 23 июнендәге ПУ-496 номерлы, 2012 елның 27 сентябрендәге ПУ-786 номерлы, 2012 елның 29 декабрендәге ПУ-1139 номерлы, 2013 елның 4 ноябрендәге ПУ-1072 номерлы һәм 2014 елның 22 сентябрендәге ПУ-910 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советының Мәгълүмати куркынычсызлык буенча ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан А.Р. Зариповны, В.В. Посоховны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Мөбарәкшин Азат Фәрит улын – Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры урынбасарын, аны Комиссия рәисе урынбасары итеп расларга;

Разинов Борис Николаевичны – Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе вазыйфаларын башкаручыны (килешү буенча);

в) Комиссия әгъзасы С.А. Антипинның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Россия Федерациясе Федераль сак хезмәтенең Татарстан Республикасында Махсус элемтә һәм мәгълүмат үзәге башлыгы (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 ел, 31 июль
№ ПУ-691